# ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ҖЫЕЛМА БАСМАСЫ

*№ 12*
*декабрь*
*2015*
*(I өлеш)*

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ
СОВЕТЫ РӘСМИ БАСМАСЫ
КАЗАН
2015

**ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ҖЫЕЛМА БАСМАСЫ:**
Татарстан Республикасы Дәүләт Советы рәсми басмасы

Формат 60x84 1/16. Тираж 32 экз.

© Татарстан Республикасы Дәүләт Советы, 2015

## Эчтәлек

# I

# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОННАРЫ

1247. «Татарстан Республикасы вәкиллекләре турында» Татарстан Республикасы Законының 12 статьясына үзгәреш кертү хакында» *Татарстан Республикасы Законы* ..... 5

1248. «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» *Татарстан Республикасы Законы* ..... 6

1249. «Мәдәният турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» *Татарстан Республикасы Законы* ..... 9

1250. «Татарстан Республикасында күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауны оештыру турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» *Татарстан Республикасы Законы* ..... 12

1251. «2015 елга, 2016 һәм 2017 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» *Татарстан Республикасы Законы* ..... 19

1252. «2015 елга, 2016 һәм 2017 еллар план чорына Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» *Татарстан Республикасы Законы* ..... 347

1253. «Россия Федерациясе файдасына Татарстан Республикасы дәүләт гарантиясе турында 2005 елның 7 декабрендәге 01-01-06/04-159 номерлы шартнамәгә 2015 елның 21 декабрендәге өстәмә килешүне раслау хакында» *Татарстан Республикасы Законы* ..... 358

1254. «Аерым муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен үзгәртү һәм «Саба муниципаль районы» му-

ниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» *Татарстан Республикасы Законы* ......................... 359

1255. «Россия Федерациясендә автомобиль транспортында һәм шәһәр җир өсте электр транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыру турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» Федераль законны гамәлгә ашыру турында» *Татарстан Республикасы Законы*.................................................... 365

1256. «Татарстан Республикасында шәһәр, авыл җирлекләренең җирле үзидарә органнары һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары арасында дәүләт милке чикләнмәгән җир кишәрлекләре белән эш итү вәкаләтләрен яңадан бүлү турында» *Татарстан Республикасы Законы*................................................ 375

1257. «Татарстан Республикасы муниципаль районнарының җирле үзидарә органнарына дәүләт милке чикләнмәгән җир кишәрлекләре белән эш итү буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» *Татарстан Республикасы Законы* .................................. 377

1258. «Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексының 8.2 статьясына үзгәреш кертү хакында» *Татарстан Республикасы Законы* ... 385



# I
# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОННАРЫ

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

### 1247. «Татарстан Республикасы вәкиллекләре турында» Татарстан Республикасы Законының 12 статьясына үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2015 елның 19 ноябрендә
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасы вәкиллекләре турында» 2003 елның 10 ноябрендәге 47-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 12 статьясындагы икенче өлешенең икенче җөмләсен (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2003, № 11; 2007, № 7 (I өлеш); 2014, № 6 (I өлеш) түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «Бер үк зат Татарстан Республикасы вәкиле вазыйфасына берничә тапкыр билгеләнеп куелырга мөмкин.».

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2015 елның 5 декабре
№ 99-ТРЗ

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

### 1248.«Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2015 елның 19 ноябрендә
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» 2004 елның 8 декабрендәге 63-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 12 (II өлеш), № 12 (III өлеш); 2005, № 2; 2006, № 2 (I өлеш); 2007, № 11; 2008, № 5 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2009, № 12 (I өлеш); 2010, № 10 (II өлеш); 2011, № 8 (I өлеш), № 10 (I өлеш); 2012, № 6 (I өлеш), № 7 (I өлеш); 2013, № 1, № 5; 2014, № 4, № 6 (II өлеш), № 7, № 12 (II өлеш); 2015, № 4) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 5 статьяда:
а) 1 пунктта:
беренче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«1. «Иминият пенсияләре турында», «Россия Федерациясендә хезмәт пенсияләре турында» һәм «Россия Федерациясендә дәүләт пенсия тәэминаты турында» федераль законнар нигезендә пенсия билгеләнгән, мөрәҗәгать иткән көнгә уртача айлык кереме күләме 20 000 сумнан артмаган хезмәт ветераннарына түбәндәге социаль ярдәм чаралары күрсәтелә:»;
бишенче абзацта «телефон, радио, коллектив антенна өчен абонент түләве» сүзләрен «чыбыклы телефон элемтәсе челтәренең абонентка даими файдалануга бирелгән абонент линиясе, радио, коллектив антенна өчен түләү» сүзләренә алмаштырырга;
алтынчы абзацта «Иминият пенсияләре турында» Федераль закон нигезендә картлык буенча пенсиягә хокук бирү яше» сүзләрен «Иминият пенсияләре турында» Федераль законның 8 статьясындагы 1 өлеше нигезендә картлык буенча иминият пенсиясенә хокук бирә торган яшькә» сүзләренә алмаштырырга;
б) 2 пунктта «Иминият пенсияләре турында» Федераль закон нигезендә картлык буенча пенсия хокукы яше» сүзләрен



«, әгәр мөрәҗәгать иткән көнгә аларның уртача айлык кереме күләме 20 000 сумнан артмаса, «Иминият пенсияләре турында» Федераль законның 8 статьясындагы 1 өлеше нигезендә картлык буенча иминият пенсиясенә хокук бирә торган яшькә» сүзләренә алмаштырырга;

2) 5[1] статьяда:
а) 1 пунктта:
дүртенче абзацта «телефон, радио, коллектив антенна өчен абонент түләве» сүзләрен «чыбыклы телефон элемтәсе челтәренең абонентка даими файдалануга бирелгән абонент линиясе, радио, коллектив антенна өчен түләү» сүзләренә алмаштырырга;
алтынчы абзацта «Иминият пенсияләре турында» Федераль закон нигезендә картлык буенча пенсия хокукы бирә торган» сүзләрен «Иминият пенсияләре турында» Федераль законның 8 статьясындагы 1 өлеше нигезендә картлык буенча иминият пенсиясенә хокук бирә торган» сүзләренә алмаштырырга;
б) 2 пунктта:
дүртенче абзацта «телефон, радио, коллектив антенна өчен абонент түләве» сүзләрен «чыбыклы телефон элемтәсе челтәренең абонентка даими файдалануга бирелгән абонент линиясе, радио, коллектив антенна өчен түләү» сүзләренә алмаштырырга;
алтынчы абзацта «Иминият пенсияләре турында» Федераль закон нигезендә картлык буенча пенсия хокукы бирә торган» сүзләрен «Иминият пенсияләре турында» Федераль законның 8 статьясындагы 1 өлеше нигезендә картлык буенча иминият пенсиясенә хокук бирә торган» сүзләренә алмаштырырга;
в) 3 пунктта:
дүртенче абзацта «телефон, радио, коллектив антенна өчен абонент түләве» сүзләрен «чыбыклы телефон элемтәсе челтәренең абонентка даими файдалануга бирелгән абонент линиясе, радио, коллектив антенна өчен түләү» сүзләренә алмаштырырга;
алтынчы абзацта «Иминият пенсияләре турында» Федераль закон нигезендә картлык буенча пенсия хокукы бирә торган» сүзләрен «Иминият пенсияләре турында» Федераль законның 8 статьясындагы 1 өлеше нигезендә картлык буенча иминият пенсиясенә хокук бирә торган» сүзләренә алмаштырырга;
г) 4 пунктта «Иминият пенсияләре турында» Федераль закон нигезендә пенсия хокукы бирелә торган» сүзләрен «Иминият пенсияләре турында» Федераль законның 8 статьясындагы 1 өлеше нигезендә картлык буенча иминият пенсиясенә хокук бирә торган» сүзләренә алмаштырырга;

3) 6 статьяның алтынчы абзацында «Иминият пенсияләре турында» Федераль закон нигезендә картлык буенча пенсиягә хокук бирү яше» сүзләрен «Иминият пенсияләре турында» Федераль законның 8 статьясындагы 1 өлеше нигезендә картлык буенча иминият пенсиясенә хокук бирә торган яшькә» сүзләренә алмаштырырга;

4) 7 статьяның бишенче абзацында «Иминият пенсияләре турында» Федераль закон нигезендә картлык буенча пенсиягә хокук бирү яше» сүзләрен «Иминият пенсияләре турында» Федераль законның 8 статьясындагы 1 өлеше нигезендә картлык буенча иминият пенсиясенә хокук бирә торган яшькә» сүзләренә алмаштырырга;

5) 8[2] статьяда:

а) 1 пунктта «Торак урыннарга мохтаҗ дип» сүзләрен «Билгеләнгән тәртиптә социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча торак урыннар бирелүгә мохтаҗ дип» сүзләренә алмаштырырга;

б) 3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Торак субсидиясе (бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү) күләмен билгеләү тәртибе һәм аны бирү тәртибе Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан раслана.».

**2 статья**

1. Әлеге Закон 2016 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

2. «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» 2004 елның 8 декабрендәге 63-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 5 статьясындагы 1 пунктының беренче абзацы һәм 2 пункты нигезләмәләре (әлеге Закон редакциясендә) социаль ярдәм чаралары әлеге Закон үз көченә кергән көнгә кадәр билгеләнгән хезмәт ветераннарына кагылмый.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2015 елның 5 декабре
№ 100-ТРЗ



# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

## 1249. «Мәдәният турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2015 елның 19 ноябрендә
кабул ителде

**1 статья**

«Мәдәният турында» 1998 елның 3 июлендәге 1705 номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 1998, № 7; 2000, № 12 (11) (II өлеш); 2006, № 12 (I өлеш); 2007, № 11; 2009, № 7 – 8 (I өлеш); 2011, № 3; 2012, № 3; 2013, № 12 (I өлеш); 2014, № 6 (II өлеш); 2015, № 3) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 4 статьяның тугызынчы абзацында «мәдәният өлкәсендә эстетик тәрбия, сәнгать белеме бирү һәм педагогик эшчәнлек» сүзләрен «эстетик тәрбия, сәнгать белеме бирү» сүзләренә алмаштырырга;

2) 6 статьяның бишенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«эстетик тәрбия һәм сәнгать белеме алуга, мәгариф турындагы законнар нигезендә эстетик тәрбия һәм сәнгать белеме алу рәвешләрен сайлауга;»;

3) 10[1] статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«10[1] статья. **Татарстан Республикасында мәдәни мирас объектларына карата Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары бурычлары**

Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары законнарда билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасында Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларын (тарихи һәм мәдәни ядкарьләрен) (алга таба – мәдәни мирас объектлары) саклап калуны, алардан файдалануны, аларны популярлаштыруны һәм дәүләт саклавын тәэмин итәләр.»;

4) 13 статьяның өченче өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы иҗади хезмәткәрләр оешмаларына мәдәният өлкәсендә Татарстан Республикасы дәүләт сәясәтен әзерләүдә катнашу мөмкинлеген тәэмин итә, мәдәният һәм сәнгать өлкәсендә кадрлар әзерләү, эш белән тәэмин итү, хезмәт шартлары буенча чаралар эшләүдә алар белән киңәшеп эш итә, әгәр Россия Федерациясе законнарында башкасы каралмаган булса, аларның эшчәнлегенә тыкшынмый.»;

5) 15 статьяда түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Россия Федерациясе законнары нигезендә башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыру.»;

6) 16 статьяда:

а) җиденче абзацны үз көчен югалткан дип танырга;

б) түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Россия Федерациясе законнары нигезендә башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыру.»;

7) 17 статьяда:

а) бишенче һәм сигезенче абзацларны үз көчләрен югалткан дип танырга;

б) түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«инвалидларга дәүләт музейларыннан, мәдәният һәм сәнгать учреждениеләреннән (исемлеген Россия Федерациясе Хөкүмәте раслый торган федераль дәүләт музейларыннан һәм исемлеген Россия Федерациясе Хөкүмәте вәкаләт биргән федераль башкарма хакимият органы раслый торган федераль мәдәният һәм сәнгать учреждениеләреннән тыш) файдалана алу шартларын тәэмин итү;

Россия Федерациясе законнары нигезендә башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыру.»;

8) 18 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«18 статья. **Мәдәният өлкәсендә җирле үзидарә органнары вәкаләтләре**

Татарстан Республикасында җирлекләрнең, муниципаль районнарның һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнары мәдәният өлкәсендә җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча вәкаләтләрне федераль законнар нигезендә башкаралар.»;



9) 19 статьяның икенче өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Мәдәният өлкәсендә милекчелек объектларын сатып алу тәртибе, аларга хуҗа булу, алардан файдалану һәм алар белән эш итү шартлары Россия Федерациясе законнары белән регламентлаштырыла.»;

10) 21 статьяның бишенче өлешендәге икенче җөмләне төшереп калдырырга;

11) 28 статьяда түбәндәге эчтәлекле алтынчы өлеш өстәргә:

«Керемнәренең бердәнбер чыганагы авторлык түләве булган иҗади берлекләр һәм ассоциацияләр әгъзалары, шулай ук иҗади берлекләр әгъзалары булмаган башка иҗади хезмәткәрләр, Россия Федерациясе Пенсия фондына иминият кертемнәре түләгән очракта, иминият пенсиясенә хокуклы.»;

12) 31 статьяның өченче абзацында «саклау һәм» сүзләрен төшереп калдырырга.

**2 статья**

Әлеге Закон, 2016 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә торган 1 статьяның 7 пунктындагы «б» пунктчасының икенче абзацыннан тыш, рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2015 елның 5 декабре
№ 101-ТРЗ

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

### 1250. «Татарстан Республикасында күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауны оештыру турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2015 елның 19 ноябрендә
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасында күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауны оештыру турында» 2013 елның 25 июнендәге 52-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2013, № 6 (II өлеш); 2014, № 5, № 11 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2 статьяда:

а) 1 өлештә:

«(алга таба – урын милекчесе)» сүзләрен («алга таба шулай ук – урын милекчесе)» сүзләренә алмаштырырга;

«һәм аңа ремонт» сүзләрен төшереп калдырырга;

б) 4 өлештә «Урыннар» сүзе алдыннан «Әлеге статьяның $4^1$ өлешендә билгеләнгән очрактан тыш,» сүзләрен өстәргә;

в) түбәндәге эчтәлекле $4^1$ өлеш өстәргә:

«$4^1$. Күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт буенча региональ программа расланганнан соң эксплуатациягә кертелгән һәм аны актуальләштергәндә күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт буенча региональ программага кертелгән күпфатирлы йортта урыннар милекчеләренең капиталь ремонт өчен кертемнәр түләү бурычы шушы күпфатирлы йорт кертелгән күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт буенча региональ программа рәсми басылып чыккан айдан соң килә торган айдан башлап биш календарь ай үткәннән соң барлыкка килә. Капиталь ремонт фонды булдыру алымын билгеләү турында карар урыннар милекчеләре тарафыннан капиталь ремонт өчен кертемнәр түләү бурычы барлыкка килгәнче өч айдан да соңга калмыйча кабул ителергә һәм гамәлгә ашырылырга тиеш.»;



г) 5 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Күпфатирлы йорттагы гомуми мөлкәт объектларын файдалануга бирүдән керемнәр, торак милекчеләре ширкәте, торак кооперативы акчалары, шул исәптән торак милекчеләре ширкәтенең, торак кооперативының хуҗалык эшчәнлегеннән алынган керемнәр, Россия Федерациясе Торак кодексы, торак милекчеләре ширкәте уставы, торак кооперативы уставы нигезендә кабул ителгән урыннар милекчеләре карары, торак милекчеләре ширкәте әгъзалары карары, торак кооперативы әгъзалары карары буенча урыннар милекчеләренең капиталь ремонт өчен кертемнәр түләү бурычын үтәү исәбенә капиталь ремонт фонды булдыруга һәм (яисә), капиталь ремонт өчен кертемнең билгеләнгән минималь күләменнән чыгып, булдырыла торган капиталь ремонт фонды өлешенә өстәп капиталь ремонт фонды өлешен булдыруга юнәлдерелергә мөмкин, ул күпфатирлы йортта гомуми мөлкәткә капиталь ремонт буенча теләсә кайсы хезмәт күрсәтүләрне һәм (яисә) эшләрне финанслау өчен тотылырга мөмкин.»;

д) 9 өлештә:

1 пунктта «, әгәр бу йортлар дәүләт күчемсез мөлкәт кадастрындагы документлар нигезендә уртак чиге булган һәм үз чикләрендә шушы йортлардагы урыннар милекчеләренең бергәләшеп файдалану өчен билгеләнгән инженерлык-техник тәэмин итү челтәрләре, инфраструктураның башка элементлары булган җир кишәрлекләрендә урнашкан булса» сүзләрен «Россия Федерациясе Торак кодексының 136 статьясындагы 2 өлешенең 1 пункты нигезендә» сүзләренә алмаштырырга;

2 пунктта «яисә башка махсуслаштырылган кулланучылар кооперативы» сүзләрен төшереп калдырырга;

$2^1$ пунктта «идарә итүче оешма» сүзләре алдыннан «күпфатирлы йортка идарә итүне идарә итү шартнамәсе нигезендә гамәлгә ашыручы» сүзләрен өстәргә;

2) 3 статьяда:

а) 1 өлештә:

5 пунктта «(еллык)» сүзен төшереп калдырырга, «күпфатирлы йортларда» сүзләре алдыннан «өч еллык срокка, күрсәтелгән срок чикләрендә елларга бүлеп,» сүзләрен өстәргә;

6 пунктта «(еллык)» сүзен төшереп калдырырга, «күпфатирлы йортларда» сүзләре алдыннан «өч еллык срокка, күрсәтелгән срок чикләрендә елларга бүлеп,» сүзләрен өстәргә;

11 пунктта «капиталь ремонт фонды» сүзләре алдыннан «әлеге Законның 2 статьясындагы $4^1$ өлешендә билгеләнгән очрактан тыш,» сүзләрен өстәргә;

түбәндәге эчтәлекле $13^{3}$ пункт өстәргә:

«$13^{3}$) капиталь ремонт фондын региональ оператор счетында, счетларында булдырган очракта региональ оператор тарафыннан яисә капиталь ремонт фондын махсус счетта булдырган очракта махсус счет хуҗасы тарафыннан, капиталь ремонт фонды булдыру алымы үзгәргәндә, тиешенчә махсус счет хуҗасына һәм (яисә) региональ операторга капиталь ремонт фонды булдыруга бәйле булган барлык документларны һәм мәгълүматны тапшыру тәртибен билгеләү;»;

б) 2 өлешнең 4 пунктын үз көчен югалткан дип танырга;

3) 4 статьяның 1 пунктында «(еллык)» сүзен төшереп калдырырга, «тиешле» сүзе алдыннан «өч еллык срокка, күрсәтелгән срок чикләрендә елларга бүлеп,» сүзләрен өстәргә;

4) 5 статьяда:

а) 4 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. Региональ оператор күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт буенча региональ программада каралган күләмдә һәм срокларда урыннар милекчеләре капиталь ремонт фондын региональ оператор счетында булдыра торган күпфатирлы йортта гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауны һәм аны финанслауны, шул исәптән капиталь ремонт фонды акчалары җитмәгән очракта, капиталь ремонт фондларын региональ оператор счетында, счетларында булдыра торган башка күпфатирлы йортлардагы урыннар милекчеләренең түләүләре исәбеннән алынган акчалар исәбеннән, Татарстан Республикасы бюджетыннан һәм (яисә) җирле бюджеттан алынган субсидияләр исәбеннән, закон белән тыелмаган башка акчалар исәбеннән тәэмин итә.»;

б) 6 өлештә «гомуми мөлкәткә» сүзләреннән соң «капиталь ремонт буенча хезмәт күрсәтүләрнең һәм (яисә)» сүзләрен, «бюджет» сүзеннән соң «һәм казна» сүзләрен өстәргә;

в) $6^{2}$ өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«$6^{2}$. Региональ оператор Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең финанс сәясәте өлкәсендәге вәкаләтле органында счетлар, махсус счетлардан тыш, ачарга хокуклы. Россия Федерациясе Торак кодексында каралган башка очракларда региональ оператор тарафыннан счетлар, махсус счетлар ачу Россия Федерациясе Торак кодексының 176 статьясындагы 2 өлешендә билгеләнгән таләпләргә туры килә торган һәм конкурс нәтиҗәләре буенча региональ оператор тарафыннан сайлап алынган Россия кредит оешмаларында гамәлгә ашырыла. Мондый конкурс уздыру тәртибе һәм шартлары Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнә.»;



5) 6 статьяның 1 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Региональ операторның күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт буенча региональ программаны финанслауга ел саен тоту хокукы булган акчалар күләме (гомуми мөлкәтенә капиталь ремонт киләсе чорда ясалырга тиешле күпфатирлы йортлардагы урыннар милекчеләре тарафыннан булдырылган капиталь ремонт фондлары акчалары исәбеннән бирелә торган акчалар күләме) региональ операторга капиталь ремонт өчен узган елда кергән кертемнәр күләменә һәм (яисә) агымдагы елда капиталь ремонт өчен кертемнәр керүнең фаразлана торган күләменә бәйле рәвештә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнә. Күрсәтелгән өлешнең күләме, региональ оператор тарафыннан алдагы чорда тотылмаган калган акчаларны исәпкә алып, региональ операторга капиталь ремонт өчен узган елда кергән кертемнәр күләменнән 92 процентны тәшкил итә.»;

6) 8 статьяда:

а) 1 өлештә:

2 пунктта «, лифтларны диспетчерлаштыру системасы белән җиһазлау» сүзләрен өстәргә;

түбәндәге эчтәлекле 13 пункт өстәргә:

«13) күпфатирлы йортларны техник инвентаризацияләү буенча эшләр үткәрү һәм техник паспортлар әзерләү.»;

б) 4 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. Күпфатирлы йортта гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауның күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт буенча региональ программада билгеләнгән срогы җиткәнче шушы күпфатирлы йортта гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясау буенча күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт буенча региональ программада каралган аерым хезмәтләр күрсәтелгән һәм (яисә) аерым эшләр башкарылган булса, бу хезмәт күрсәтүләргә һәм (яисә) эшләргә түләү бюджет акчаларыннан һәм региональ оператор акчаларыннан файдаланмыйча гына гамәлгә ашырылган булса һәм шул ук вакытта күпфатирлы йортта гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясау кирәклеген билгеләү тәртибендә әлеге хезмәтләрне яңадан күрсәтү һәм (яисә) эшләрне яңадан эшләү күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт буенча региональ программада билгеләнгән срокта таләп ителмәсә, шушы хезмәт күрсәтүләрнең һәм (яисә) эшләрнең хакына тигез булган, әмма әлеге хезмәт күрсәтүләр һәм (яисә) эшләр хакының Россия Федерациясе Торак кодексының 190 статьясындагы 4 өлеше нигезендә билгеләнгән иң чик күләменнән артык булмаган күләмдәге акчалар капиталь ремонт фондларын булдыручы

урыннар милекчеләренең региональ оператор счетына, счетларына капиталь ремонт өчен кертемнәр түләү йөкләмәләрен киләчәк чорга үтәү исәбенә кертеләләр.»;

7) 10 статьяда:

а) 4 өлештә:

3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3) Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан (шул исәптән барлык биналары бер милекчегә караган күпфатирлы йортлар) һәм җирле үзидарә органнары тарафыннан расланган муниципаль адреслы программаларга кертелгән барлык күпфатирлы йортлар исемлеге, моңа Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән тәртиптә авария хәлендә һәм сүтелергә яисә реконструкцияләнергә тиеш дип танылган күпфатирлы йортлар керми;»;

5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5) күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауның план чоры, шул исәптән хезмәт күрсәтүләрнең һәм (яисә) эшләрнең һәр төре буенча башкару сроклары, шул ук вакытта күрсәтелгән срок календарь елны яисә мондый ремонт ясалырга тиешле өч календарь елдан артып китмәгән чорны күрсәтеп билгеләнергә мөмкин;»

б) 10 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«10. Капиталь ремонт буенча региональ программага күпфатирлы йорттагы гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауның билгеләнгән срогын соңрак чорга күчерүне, күпфатирлы йортта гомуми мөлкәткә капиталь ремонт буенча планлаштырыла торган хезмәт күрсәтүләр һәм (яисә) эшләр төре исемлеген кыскартуны күздә тота торган үзгәрешләр кертү урыннар милекчеләре гомуми җыелышының тиешле карары булганда гамәлгә ашырыла, аңа түбәндәге очраклар керми:

1) күпфатирлы йортта гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясау буенча планлаштырылган хезмәт күрсәтүләр һәм (яисә) эшләр төренең исемлеген кыскарту капиталь ремонт үткәрелергә тиешле конструктив элементларның булмавына бәйле булса;

2) күпфатирлы йортта гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясау буенча хезмәт күрсәтүләрнең һәм (яки) эшләрнең планлаштырылган төрләре алданрак үткәрелгән булса һәм шул ук вакытта күпфатирлы йортта гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясау кирәклеген билгеләү тәртибендә яңадан мондый хезмәтләр күрсәтү һәм (яисә) эшләр башкару капиталь ремонт буенча региональ программада билгеләнгән срокта таләп ителми дип табылса;

3) капиталь ремонт фонды булдыру ысулын үзгәртү Россия Федерациясе Торак кодексының 189 статьясының 7 өлешендә



каралган нигезләрдә башкарылса. Бу очракта капиталь ремонт ясау вакыты күпфатирлы йортта гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясау кирәклеген билгеләү тәртибендә ачыклана.»;

в) түбәндәге эчтәлекле $10^1$ өлеш өстәргә:

«$10^1$. Капиталь ремонт буенча региональ программага үзгәрешләр кертү турындагы карарлар торак-коммуналь хуҗалык өлкәсендә дәүләт сәясәтен эшләү һәм гамәлгә ашыру, норматив-хокукый җайга салу функцияләрен башкаручы федераль башкарма хакимият органы раслаган методик тәкъдимнәр нигезендә кабул ителә.»;

г) 11 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«11. Капиталь ремонт буенча региональ программаны гамәлгә ашыру, күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясау срокларын конкретлаштыру, күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт буенча планлаштырыла торган хезмәт күрсәтүләр һәм (яисә) эшләр төрен төгәлләштерү, капиталь ремонт ясауга дәүләт ярдәме, муниципаль ярдәм төрләрен һәм күләмен билгеләү максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты капиталь ремонт буенча региональ программаны гамәлгә ашыруның кыска сроклы планнарын, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнгән тәртиптә, өч еллык срок кысаларында елларга бүлеп, күрсәтелгән срокка расларга тиеш. Капиталь ремонт буенча региональ программаны гамәлгә ашыруның кыска сроклы планына әлеге статьяның 10 өлешендә каралган нигезләрдә үзгәрешләр кертелгәндә, урыннар милекчеләре белән килештерү таләп ителми.»;

д) түбәндәге эчтәлекле $11^1$ өлеш өстәргә:

«$11^1$. Җирле үзидарә органнары капиталь ремонт буенча региональ программаны гамәлгә ашыруның кыска сроклы планнарын, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнгән тәртиптә, өч еллык срок кысаларында елларга бүлеп, күрсәтелгән срокка расларга тиеш.»;

8) 12 статьяның 2 өлешендәге 5 пунктын үз көчен югалткан дип таныргa;

9) 13 статьяның 2 өлешендә «яисә башка махсуслаштырылган кулланучылар кооперативларына» сүзләрен төшереп калдырырга.

**2 статья**

1. Әлеге Закон, үз көченә керүнең әлеге статьяда башка сроклар билгеләнгән нигезләмәләрдән кала, рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

2. Әлеге Законның 1 статьясындагы 2 пунктының «б» пунктчасы нигезләмәсе Россия Федерациясе Хөкүмәтенең тиешле акты үз көченә кергән көннән соң 90 көн узгач кулланыла. Күрсәтелгән срокка кадәр региональ операторның, шул исәптән Россия Федерациясе Торак кодексында каралган очракларда, җирле үзидарә органнарының, муниципаль бюджет учреждениеләренең күпфатирлы йортта гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясау буенча хезмәт күрсәтүләр өчен һәм (яисә) эшләр башкару өчен подряд оешмаларын җәлеп итү тәртибе Татарстан Республикасы башкарма хакимияте вәкаләтле органының норматив хокукый акты белән билгеләнә.

3. «Татарстан Республикасында күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауны оештыру турында» 2013 елның 25 июнендәге 52-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының (әлеге Закон редакциясендә) 5 статьясындагы $6^2$ өлеше нигезләмәләре, региональ операторлар тарафыннан Россия Федерациясе Торак кодексының 176 статьясының 2 өлеше таләпләренә туры килә торган Россия кредит оешмаларын Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән тәртиптә һәм шартларда конкурс нәтиҗәләре буенча сайлап алу өлешендә, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең тиешле акты үз көченә кергән көннән соң 90 көн узгач кулланыла. Күрсәтелгән срокка кадәр «Татарстан Республикасында күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауны оештыру турында» 2013 елның 25 июнендәге 52-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының (әлеге Закон редакциясендә) 5 статьясындагы $6^2$ өлешендә күрсәтелгән конкурсны үткәрү тәртибе һәм аның шартлары Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнә.

4. Әлеге Законның 1 статьясындагы 2 пунктының «а» пунктчасындагы икенче һәм өченче абзацлары, 3 пункт, 7 пунктындагы «а» пунктчасының дүртенче һәм бишенче абзацлары, «г» пунктчасы, «д» пунктчасы 2017 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

5. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты әлеге Законның үтәлешен тәэмин итә торган норматив хокукый актлар кабул итәргә тиеш.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2015 елның 5 декабре
№ 102-ТРЗ



# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

## 1251. «2015 елга, 2016 һәм 2017 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2015 елның 23 декабрендә
кабул ителде

**1 статья**

«2015 елга, 2016 һәм 2017 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында» 2014 елның 27 ноябрендәге 107-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2014, № 11 (V өлеш), № 11 (VI өлеш); 2015, № 1 – 2, № 7 (I өлеш), № 10 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 статьяның 1 өлешендә:
а) 1 пунктта «191 320 622,4» саннарын «201 386 500,3» саннарына алмаштырырга;
б) 2 пунктта «208 118 047,2» саннарын «212 235 518,2» саннарына алмаштырырга;
в) 3 пунктта «16 797 424,8» саннарын «10 849 017,9» саннарына алмаштырырга;

2) 2 статьяда:
а) 1 өлештә «94 557 582,3» саннарын «92 076 905,4» саннарына алмаштырырга, «7 265 720,0» саннарын «10 733 450,0» саннарына алмаштырырга;
б) 4 өлешнең икенче абзацында «127 872 034,3» саннарын «125 391 357,4» саннарына алмаштырырга;

3) 8 статьяның 3 өлешендә «17 792 695,4» саннарын «16 861 540,7» саннарына алмаштырырга;

4) 14 статьяның 2 өлешендә:
а) беренче абзацта «6 696 701,2» саннарын «6 685 130,5» саннарына алмаштырырга;
б) икенче абзацта «853 004,6» саннарын «785 139,5» саннарына алмаштырырга;

5) 15 статьяда «13 389 228,2» саннарын «14 133 403,2» саннарына алмаштырырга;

6) 19 статьяда:
а) икенче абзацта «28 721 163,2» саннарын «31 407 416,0» саннарына алмаштырырга;
б) дүртенче абзацта «10 955,8» саннарын «11 388,6» саннарына алмаштырырга;
в) бишенче абзацта «1 270 032,2» саннарын «943 296,5» саннарына алмаштырырга;
г) алтынчы абзацта «501 648,0» саннарын «408 500,0» саннарына алмаштырырга;

7) 1 нче кушымтаның 1 нче таблицасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1 нче таблица

2015 елга
Татарстан Республикасы бюджеты кытлыгын финанслау чыганаклары

(мең сумнарда)

| Күрсәткеч коды | Күрсәткеч исеме | Суммасы |
|---|---|---|
| 01 00 00 00 00 0000 000 | Бюджетлар кытлыкларын эчке финанслау чыганаклары | 10 849 017,9 |
| 01 03 00 00 00 0000 000 | Россия Федерациясе бюджет системасының башка бюджетларыннан бюджет кредитлары | 8 937 548,0 |
| 01 03 01 00 00 0000 000 | Россия Федерациясе бюджет системасының башка бюджетларыннан Россия Федерациясе валютасында бирелгән бюджет кредитлары | 8 937 548,0 |
| 01 03 01 00 00 0000 700 | Россия Федерациясе бюджет системасының башка бюджетларыннан Россия Федерациясе валютасында бюджет кредитлары алу | 92 139 000,0 |
| 01 03 01 00 02 0000 710 | Россия Федерациясе бюджет системасының башка бюджетларыннан Россия Федерациясе валютасында Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына кредитлар алу | 92 139 000,0 |
| 01 03 01 00 00 0000 800 | Россия Федерациясе бюджет системасының башка бюджетларыннан Россия Федерациясе валютасында алынган бюджет кредитларын каплау | -83 201 452,0 |
| 01 03 01 00 02 0000 810 | Россия Федерациясе бюджет системасының башка бюджетларыннан Россия Федерациясе валютасында алынган кредитларны Россия Федерациясе субъектлары бюджетларыннан каплау | -83 201 452,0 |



| Күрсәткеч коды | Күрсәткеч исеме | Суммасы |
|---|---|---|
| 01 05 00 00 00 0000 000 | Бюджетлар чараларын исәпкә алу счетларында калган чараларны үзгәртү | 1 925 652,3 |
| 01 05 00 00 00 0000 500 | Бюджетларның калган чараларын арттыру | -304 264 267,9 |
| 01 05 02 00 00 0000 500 | Бюджетларның калган башка чараларын арттыру | -304 264 267,9 |
| 01 05 02 01 00 0000 510 | Бюджетларның калган башка акчаларын арттыру | -304 264 267,9 |
| 01 05 02 01 02 0000 510 | Россия Федерациясе субъектлары бюджетларының калган башка акчаларын арттыру | -304 264 267,9 |
| 01 05 00 00 00 0000 600 | Бюджетларның калган чараларын киметү | 306 189 920,2 |
| 01 05 02 00 00 0000 600 | Бюджетларның калган башка чараларын киметү | 306 189 920,2 |
| 01 05 02 01 00 0000 610 | Бюджетларның калган башка акчаларын киметү | 306 189 920,2 |
| 01 05 02 01 02 0000 610 | Россия Федерациясе субъектлары бюджетларының калган башка акчаларын киметү | 306 189 920,2 |
| 01 06 00 00 00 0000 000 | Бюджетлар кытлыкларын эчке финанслауның башка чыганаклары | -14 182,4 |
| 01 06 01 00 00 0000 000 | Дәүләт һәм муниципаль милектәге акцияләр һәм капиталда катнашуның бүтән рәвешләре | 5 000,0 |
| 01 06 01 00 00 0000 630 | Дәүләт һәм муниципаль милектәге акцияләрне һәм капиталда катнашуның бүтән рәвешләрен сатудан акчалар | 5 000,0 |
| 01 06 01 00 02 0000 630 | Россия Федерациясе субъектлары милкендәге акцияләрне һәм капиталда катнашуның бүтән рәвешләрен сатудан акчалар | 5 000,0 |
| 01 06 04 00 00 0000 000 | Дәүләт һәм муниципаль гарантияләрне үтәү | -10 733 450,0 |
| 01 06 04 02 00 0000 000 | Дәүләт һәм муниципаль гарантияләрне чит ил валютасында үтәү | -10 733 450,0 |
| 01 06 04 02 00 0000 800 | Дәүләт һәм муниципаль гарантияләрне гарант тарафыннан үтәү принципалга карата гарантның регресс таләбе хокукын барлыкка китергән очракта, максатчан чит ил кредитларыннан (хисаплашулардан) файдалану кысаларында Россия Федерациясенә бирелгән дәүләт һәм муниципаль гарантияләрне чит ил валютасында үтәү | -10 733 450,0 |
| 01 06 04 02 02 0000 820 | Россия Федерациясе субъекты дәүләт гарантияләрен гарант тарафыннан үтәү принципалга карата гарантның регресс таләбе хокукын барлыкка китергән очракта, максатчан чит ил кредитларыннан (хисаплашулардан) файдалану кысаларында Россия Федерациясенә бирелгән Россия Федерациясе субъекты дәүләт гарантияләрен чит ил валютасында үтәү | -10 733 450,0 |

| Күрсәткеч коды | Күрсәткеч исеме | Суммасы |
|---|---|---|
| 01 06 05 00 00 0000 000 | Ил эчендә Россия Федерациясе валютасында бирелгән бюджет кредитлары | -19 182,4 |
| 01 06 05 00 00 0000 600 | Ил эчендә Россия Федерациясе валютасында бирелгән бюджет кредитларын кире кайтару | 317,6 |
| 01 06 05 01 00 0000 600 | Юридик затларга Россия Федерациясе валютасында бирелгән бюджет кредитларын кире кайтару | 317,6 |
| 01 06 05 01 02 0000 640 | Россия Федерациясе субъектлары бюджетларыннан юридик затларга Россия Федерациясе валютасында бирелгән бюджет кредитларын кире кайтару | 317,6 |
| 01 06 05 00 00 0000 500 | Ил эчендә Россия Федерациясе валютасында бюджет кредитлары бирү | -19 500,0 |
| 01 06 05 02 00 0000 500 | Россия Федерациясе бюджет системасының башка бюджетларына Россия Федерациясе валютасында бюджет кредитлары бирү | -19 500,0 |
| 01 06 05 02 02 0000 540 | Россия Федерациясе бюджет системасының башка бюджетларына Россия Федерациясе субъектлары бюджетыннан Россия Федерациясе валютасында бюджет кредитлары бирү | -19 500,0 |
| 01 06 08 00 00 0000 000 | Ил эчендә бирелгән башка бюджет кредитлары (ссудалары) | 10 733 450,0 |
| 01 06 08 00 00 0000 600 | Ил эчендә бирелгән башка бюджет кредитларын (ссудаларын) кире кайтару | 10 733 450,0 |
| 01 06 08 00 02 0000 640 | Ил эчендә Россия Федерациясе субъектлары бюджетыннан бирелгән башка бюджет кредитларын (ссудаларын) кире кайтару | 10 733 450,0 |
| Барлык чыганаклар | | 10 849 017,9»; |

8) 2 нче кушымтаның 1 нче таблицасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1 нче таблица

### 2015 елга Татарстан Республикасы эчке дәүләт хисаплашулары программасы

(мең сумнарда)

| | Суммасы |
|---|---|
| Эчке дәүләт хисаплашулары<br>жәлеп итү<br>бурычның төп суммасын каплауга җибәрелә торган акчалар күләме | <br>92 139 000,0<br>83 201 452,0 |



| | Суммасы |
|---|---|
| шул исәптән:<br>бюджет кредитлары<br>җәлеп итү<br>бурычның төп суммасын каплауга җибәрелә торган акчалар күләме,<br>шул исәптән: | <br><br>92 139 000,0<br>83 201 452,0 |
| Россия Федерациясе субъектлары бюджетлары счетларында калган акчаларга өстәү өчен федераль бюджеттан бюджет кредитлары<br>җәлеп итү<br>бурычның төп суммасын каплауга җибәрелә торган акчалар күләме | <br><br>83 139 000,0<br>83 139 000,0 |

»;

9) 3 нче кушымтаның 1 нче таблицасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1 нче таблица

### 2015 елга Татарстан Республикасы бюджеты керемнәренең фаразлана торган күләмнәре

(мең сумнарда)

| Исеме | Керем коды | Суммасы |
|---|---|---|
| Салым керемнәре һәм салым булмаган керемнәр | 1 00 00000 00 0000 000 | 167 276 275,3 |
| Табышка, керемнәргә салымнар | 1 01 00000 00 0000 000 | 110 889 294,3 |
| Оешмалар табышына салым | 1 01 01000 00 0000 110 | 70 791 860,3 |
| Физик затлар керемнәренә салым | 1 01 02000 01 0000 110 | 40 097 434,0 |
| Россия Федерациясе территориясендә реализацияләнә торган товарларга (эшләргә, хезмәт күрсәтүләргә) салымнар | 1 03 00000 00 0000 000 | 19 886 327,0 |
| Россия Федерациясе территориясендә җитештерелә торган акцизлы товарларга (продукциягә) акцизлар | 1 03 02000 01 0000 110 | 19 886 327,0 |
| Җыелма керемгә салымнар | 1 05 00000 00 0000 000 | 3 800 740,0 |
| Салым салуның гадиләштерелгән системасын куллануга бәйле рәвештә алына торган салым | 1 05 01000 00 0000 110 | 3 800 740,0 |
| Мөлкәткә салымнар | 1 06 00000 00 0000 000 | 24 971 323,0 |
| Оешмалар мөлкәтенә салым | 1 06 02000 02 0000 110 | 20 553 224,0 |
| Транспорт салымы | 1 06 04000 02 0000 110 | 4 412 004,0 |
| Уен бизнесына салым | 1 06 05000 02 0000 110 | 6 095,0 |
| Табигать ресурсларыннан файдаланган өчен салымнар, җыемнар һәм даими түләүләр | 1 07 00000 00 0000 000 | 76 827,0 |
| Файдалы казылмалар чыгаруга салым | 1 07 01000 01 0000 110 | 75 529,0 |
| Хайваннар дөньясы объектларыннан файдаланган һәм су биологик ресурслары объектларыннан файдаланган өчен җыемнар | 1 07 04000 01 0000 110 | 1 298,0 |
| Дәүләт пошлинасы | 1 08 00000 00 0000 000 | 567 546,0 |

| Исеме | Керем коды | Суммасы |
|---|---|---|
| Россия Федерациясе гражданлыгын алуга яисә Россия Федерациясе гражданлыгыннан чыгуга бәйле, шулай ук Россия Федерациясенә керүгә яисә Россия Федерациясеннән чыгуга бәйле гамәлләр кылган өчен дәүләт пошлинасы | 1 08 06000 01 0000 110 | 2 120,0 |
| Дәүләт теркәвенә алган, шулай ук бүтән юридик әһәмиятле гамәлләр кылган өчен дәүләт пошлинасы | 1 08 07000 01 0000 110 | 565 426,0 |
| Юкка чыгарылган салымнар, җыемнар һәм башка мәҗбүри түләүләр буенча бурычлар һәм яңадан исәпләүләр | 1 09 00000 00 0000 000 | 11 673,0 |
| Дәүләт милкендәге һәм муниципаль милектәге мөлкәттән файдаланудан керемнәр | 1 11 00000 00 0000 000 | 654 408,2 |
| Хуҗалык ширкәтләренең һәм җәмгыятьләренең устав (җыелма) капиталларындагы өлешләренә туры килә торган табыш яисә Россия Федерациясенең, Россия Федерациясе субъектларының яисә муниципаль берәмлекләрнең акцияләре буенча дивидендлар рәвешендәге керемнәр | 1 11 01000 00 0000 120 | 140 961,4 |
| Ил эчендә бюджет кредитлары бирүдән алынган процентлар | 1 11 03000 00 0000 120 | 128 641,7 |
| Дәүләт һәм муниципаль мөлкәтне (бюджет һәм автоном учреждениеләр мөлкәтеннән, шулай ук дәүләт һәм муниципаль унитар предприятиеләр, шул исәптән казна предприятиеләре мөлкәтеннән тыш) түләүле файдалануга тапшырган өчен аренда түләве йә башка түләү рәвешендә алына торган керемнәр | 1 11 05000 00 0000 120 | 286 176,0 |
| Дәүләт һәм муниципаль унитар предприятиеләрдән түләүләр | 1 11 07000 00 0000 120 | 45 933,0 |
| Дәүләт милкендәге һәм муниципаль милектәге мөлкәтне (бюджет һәм автоном учреждениеләр мөлкәтеннән, шулай ук дәүләт һәм муниципаль унитар предприятиеләр, шул исәптән казна предприятиеләре мөлкәтеннән тыш) залогка, ышанычлы идарәгә тапшырудан алына торган акчалар | 1 11 08000 00 0000 120 | 52 668,4 |
| Дәүләт милкендәге һәм муниципаль милектәге мөлкәттән (бюджет һәм автоном учреждениеләр мөлкәтеннән, шулай ук дәүләт һәм муниципаль унитар предприятиеләр, шул исәптән казна предприятиеләре мөлкәтеннән тыш) һәм хокуклардан файдаланган өчен башка керемнәр | 1 11 09000 00 0000 120 | 27,7 |
| Табигать ресурсларыннан файдаланганда түләүләр | 1 12 00000 00 0000 000 | 409 054,0 |
| Әйләнә-тирә мохиткә тискәре йогынты ясаган өчен түләү | 1 12 01000 01 0000 120 | 344 600,0 |
| Җир асты байлыкларыннан файдаланганда түләүләр | 1 12 02000 00 0000 120 | 58 632,0 |
| Урманнардан файдаланган өчен түләү | 1 12 04000 00 0000 120 | 5 822,0 |



| Исеме | Керем коды | Суммасы |
|---|---|---|
| Түләүле хезмәт күрсәтүләрдән (эшләр башкарудан) һәм дәүләт чыгымнарын компенсацияләүдән керемнәр | 1 13 00000 00 0000 000 | 1 529 351,3 |
| Түләүле хезмәт күрсәтүләрдән (эшләр башкарудан) керемнәр | 1 13 01000 00 0000 130 | 119 554,3 |
| Дәүләт чыгымнарын компенсацияләүдән керемнәр | 1 13 02000 00 0000 130 | 1 409 797,0 |
| Матди һәм матди булмаган активларны сатудан керемнәр | 1 14 00000 00 0000 000 | 369 164,0 |
| Дәүләт милкендәге һәм муниципаль милектәге мөлкәтне (бюджет һәм автоном учреждениеләрнең күчемле мөлкәтеннән, шулай ук дәүләт һәм муниципаль унитар предприятиеләр, шул исәптән казна предприятиеләре мөлкәтеннән тыш) реализацияләүдән керемнәр | 1 14 02000 00 0000 000 | 283 664,0 |
| Дәүләт милкендәге һәм муниципаль милектәге җир кишәрлекләрен сатудан керемнәр | 1 14 06000 00 0000 430 | 85 500,0 |
| Административ түләүләр һәм җыемнар | 1 15 00000 00 0000 000 | 1 366,0 |
| Дәүләт һәм муниципаль органнар (оешмалар) тарафыннан аерым функцияләр башкарган өчен алына торган түләүләр | 1 15 02000 00 0000 140 | 1 242,0 |
| Дәүләт экологик экспертизасы үткәрелергә тиешле документация заказчылары тарафыннан кертелә торган дәүләт экологик экспертизасы үткәрүгә чыгымнар сметасы нигезендә исәпләнгән җыемнар | 1 15 07000 01 0000 140 | 124,0 |
| Штрафлар, санкцияләр, зыянны каплау | 1 16 00000 00 0000 000 | 3 631 001,5 |
| Товар базарларында конкуренцияне, финанс хезмәтләре күрсәтү базарында конкуренцияне яклау өлкәсендә монополиягә каршы законнарны, табигый монополияләр турындагы законнарны һәм бәяләрне (тарифларны) дәүләт тарафыннан җайга салу турындагы законнарны бозган өчен акчалата түләтүләр (штрафлар) | 1 16 02000 00 0000 140 | 3 440,0 |
| Салымнар һәм җыемнар турындагы законнар-ны бозган өчен акчалата түләтүләр (штрафлар) | 1 16 03000 00 0000 140 | 32,0 |
| Россия Федерациясе бюджет законнарын бозган өчен акчалата түләтүләр (штрафлар) | 1 16 18000 00 0000 140 | 20,0 |
| Җинаятьләр кылуда һәм мөлкәткә зыян китерүдә гаепле затлардан алына торган акчалата түләтүләр (штрафлар) һәм башка суммалар | 1 16 21000 00 0000 140 | 1,2 |
| Иминият очраклары барлыкка килгәндә зыян каплаудан керемнәр | 1 16 23000 00 0000 140 | 328,0 |
| Җир асты байлыклары турында, махсус сакланылучы табигать территорияләре турында, хайваннар дөньясын саклау һәм алардан файдалану турында, экологик экспертиза турында, әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендә, балыкчылык һәм су биологик ресурсларын саклау турында, җир законнары, урман законнары, су законнары турында Россия Федерациясе законнарын бозган өчен акчалата түләтүләр (штрафлар) | 1 16 25000 00 0000 140 | 1 224,0 |

| Исеме | Керем коды | Суммасы |
|---|---|---|
| Реклама турындагы законнарны бозган өчен акчалата түләтүләр (штрафлар) | 1 16 26000 01 0000 140 | 1 236,0 |
| Янгын куркынычсызлыгы турында Россия Федерациясе законнарын бозган өчен акчалата түләтүләр (штрафлар) | 1 16 27000 01 0000 140 | 18 966,0 |
| Юл хәрәкәте өлкәсендә хокук бозулар өчен акчалата түләтүләр (штрафлар) | 1 16 30000 01 0000 140 | 3 584 700,0 |
| Бюджет акчаларыннан законлы яисә максатчан файдаланмау аркасында китерелгән зыянны каплауга салына торган акчалата түләтүләр | 1 16 32000 00 0000 140 | 17,0 |
| Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алу өлкәсендә контракт системасы турындагы Россия Федерациясе законнарын бозган өчен акчалата түләтүләр (штрафлар) | 1 16 33000 00 000 140 | 3 800,0 |
| Әйләнә-тирә мохиткә китерелгән зыянны түләтү турындагы дәгъвалар буенча суммалар | 1 16 35000 00 0000 140 | 2 175,0 |
| Бюджет кредитлары бирү турындагы шартнамәләрнең (килешүләрнең) шартларын бозган өчен акчалата түләтүләр (штрафлар) | 1 16 42000 00 0000 140 | 4,0 |
| Зыянны каплауга акчалата түләтүләрдән (штрафлардан) һәм башка суммалардан бүтән кертемнәр | 1 16 90000 00 0000 140 | 15 058,3 |
| Салым булмаган башка керемнәр | 1 17 00000 00 0000 000 | 478 200,0 |
| Салым булмаган башка керемнәр | 1 17 05000 00 0000 180 | 478 200,0 |
| Кире кайтарылмый торган кертемнәр | 2 00 00000 00 0000 000 | 34 110 225,0 |
| Россия Федерациясе бюджет системасының башка бюджетларыннан керүче кире кайтарылмый торган кертемнәр | 2 02 00000 00 0000 000 | 32 141 308,9 |
| Россия Федерациясе субъектлары һәм муниципаль берәмлекләре бюджетларына дотацияләр | 2 02 01000 00 0000 151 | 1 465 140,9 |
| Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына субсидияләр (бюджетара субсидияләр) | 2 02 02000 00 0000 151 | 17 029 470,1 |
| Россия Федерациясе субъектлары һәм муниципаль берәмлекләр бюджетларына субвенцияләр | 2 02 03000 00 0000 151 | 8 254 963,0 |
| Башка бюджетара трансфертлар | 2 02 04000 00 0000 151 | 5 390 996,3 |
| Бюджет системасының башка бюджетларыннан керүче кире кайтарылмый торган башка кертемнәр | 2 02 09000 00 0000 151 | 738,6 |
| Дәүләт (муниципаль) оешмаларыннан керүче кире кайтарылмый торган кертемнәр | 2 03 00000 00 0000 000 | 943 296,5 |
| Дәүләтнеке булмаган оешмалардан кире кайтарылмый торган кертемнәр | 2 04 00000 00 0000 000 | 408 500,0 |
| Кире кайтарылмый торган башка кертемнәр | 2 07 00000 00 0000 000 | 75 721,4 |
| Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына кире кайтарылмый торган башка кертемнәр | 2 07 02000 02 0000 180 | 75 721,4 |



| Исеме | Керем коды | Суммасы |
|---|---|---|
| Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетлары һәм оешмалар тарафыннан узган еллардагы субсидияләрнең, субвенцияләрнең һәм максатчан билгеләнешкә ия бүтән бюджетара трансфертларның калган өлешләрен кайтарудан Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетлары керемнәре | 2 18 00000 00 0000 000 | 621 282,5 |
| Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетлары тарафыннан узган еллардагы субсидияләрнең, субвенцияләрнең һәм максатчан билгеләнешкә ия бүтән бюджетара трансфертларның калган өлешләрен кайтарудан Россия Федерациясе субъектлары бюджетлары керемнәре | 2 18 02000 02 0000 151 | 621 282,5 |
| Узган еллардагы максатчан билгеләнешкә ия субсидияләрнең, субвенцияләрнең һәм башка бюджетара трансфертларның калган өлешләрен кайтару | 2 19 00000 00 0000 000 | -79 884,3 |
| Узган еллардагы Россия Федерациясе субъектлары бюджетларыннан максатчан билгеләнешкә ия субсидияләрнең, субвенцияләрнең һәм башка бюджетара трансфертларның калган өлешләрен кайтару | 2 19 02000 02 0000 151 | -79 884,3 |
| Барлык керемнәр | | 201 386 500,3»; |

10) 6 нчы кушымтада:

а)

| | | |
|---|---|---|
| «000 | 2 02 02073 02 0000 151 | Технопарклар төзүгә Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына субсидияләр» |

юлын төшереп калдырырга;

б)

| | | |
|---|---|---|
| «000 | 2 02 02082 02 0000 151 | Химияләштерү чараларын сатып алу чыгымнары өлешен компенсацияләүгә Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына субсидияләр |
| 000 | 2 02 02085 02 0000 151 | Авыл җирендә яшәүче Россия Федерациясе гражданнарын торак белән тәэмин итү гамәлләрен башкаруга Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына субсидияләр» |

юлларын төшереп калдырырга;

в)

| | | |
|---|---|---|
| «000 | 2 02 02210 02 0000 151 | Энергияне сак тоту һәм энергетика нәтиҗәлелеген арттыру өлкәсендәге региональ программаларны гамәлгә ашыруга Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына субсидияләр» |

юлын төшереп калдырырга;

г)

«000 2 02 04065 02 0000 151 Кан хезмәтен үстерү чараларын гамәлгә ашыру өчен лицензияле программалар белән тәэмин ителгән компьютерлар һәм челтәр җиһазларын сатып алуларны финанс белән тәэмин итүгә Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына тапшырыла торган бюджетара трансфертлар»

юлын төшереп калдырырга;

11) 8 нче кушымтаның 1 нче таблицасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1 нче таблица

2015 елга Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнарының ведомство структурасы

(мең сумнарда)

| Исеме | КВСР | Рз | ПР | ЦСР | ВР | Суммасы |
|---|---|---|---|---|---|---|
| Татарстан Республикасы Экология һәм табигать байлыклары министрлыгы | 701 | | | | | 503 050,8 |
| Гомумдәүләт мәсьәләләре | 701 | 01 | | | | 206,9 |
| Башка гомумдәүләт мәсьәләләре | 701 | 01 | 13 | | | 206,9 |
| Чыгымнарның программада каралмаган юнәлешләре | 701 | 01 | 13 | 99 0 0000 | | 206,9 |
| «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләрен мәҗбүри дәүләт иминләштерүе турында» 2012 елның 14 июлендәге 55-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын гамәлгә ашыру | 701 | 01 | 13 | 99 0 9231 | | 206,9 |
| Дәүләт (муниципаль) ихтыяҗлары өчен товарлар, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр сатып алу | 701 | 01 | 13 | 99 0 9231 | 200 | 206,9 |
| Милли икътисад | 701 | 04 | | | | 173 323,0 |
| Минерал-чимал базасын торгызу | 701 | 04 | 04 | | | 47 483,8 |
| «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасы әйләнә-тирә мохитен саклау, табигать ресурсларын торгызу һәм алардан файдалану» дәүләт программасы | 701 | 04 | 04 | 09 0 0000 | | 47 483,8 |
| «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасы җир асты байлыкларыннан файдалану өлкәсендә дәүләт идарәсе» ярдәмче программасы | 701 | 04 | 04 | 09 3 0000 | | 47 483,8 |
| Җир асты байлыкларын геологик өйрәнү һәм минерал-чимал базасын торгызу гамәлләре | 701 | 04 | 04 | 09 3 8510 | | 47 483,8 |



| Исеме | КВСР | Рз | ПР | ЦСР | ВР | Суммасы |
|---|---|---|---|---|---|---|
| Дәүләт (муниципаль) ихтыяҗлары өчен товарлар, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр сатып алу | 701 | 04 | 04 | 09 3 8510 | 200 | 47 483,8 |
| Су хуҗалыгы | 701 | 04 | 06 | | | 125 839,2 |
| «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасы әйләнә-тирә мохитен саклау, табигать ресурсларын торгызу һәм алардан файдалану» дәүләт программасы | 701 | 04 | 06 | 09 0 0000 | | 125 839,2 |
Әлеге Закон «Россия Федерациясендә автомобиль транспортында һәм шәһәр җир өсте электр транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыру турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2015 елның 13 июлендәге 220-ФЗ номерлы Федераль законны (алга таба – Федераль закон) гамәлгә ашыру максатларында даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыру өлкәсендә Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары һәм җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен, даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципальара һәм муниципаль маршрутлары буенча даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм багаж ташу маршрутларын билгеләү, үзгәртү, туктату, даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм багаж ташу маршрутлары реестрларын алып бару һәм даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыруның башка нигезләрен билгели.

2 статья. **Даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыру мөнәсәбәтләрен хокукый җайга салу**

Даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыру мөнәсәбәтләрен хокукый җайга салу федераль законнар һәм Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актлары, әлеге Закон һәм Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актлары, шулай ук җирле үзидарә органнарының норматив хокукый актлары нигезендә гамәлгә ашырыла.

3 статья. **Даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыру өлкәсендә Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары вәкаләтләре**

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыру өлкәсендә:

1) үз компетенциясе чикләрендә даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыруны җайга сала торган Татарстан Республикасы норматив хокукый актларын кабул итә;

2) үз компетенциясе чикләрендә даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны планлаштыру документын әзерләү тәртибен раслый, бу документны кабул итә һәм аны гамәлгә ашыруны оештыра;

3) йөртүчеләрнең транспортта йөрүгә ташламалардан файдаланучы пассажирларны йөртүгә бәйле чыгымнарын исәпләү методикасын һәм аларны Татарстан Республикасы бюджеты акчаларыннан каплау тәртибен раслый;

4) федераль законнар, әлеге Закон һәм Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актлары нигезендә башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыра.

2. Даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыру өлкәсендә вәкаләтле Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органы (алга таба – вәкаләтле Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органы):

1) даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыруны җайга сала торган Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары проектларын эшли;

2) үз компетенциясе чикләрендә даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны планлаштыру документын эшли һәм аны гамәлгә ашыра;

3) даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципальара маршрутлары буенча даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның дәүләт заказчысы функцияләрен башкара, дәүләт контрактын төзи, дәүләт контракты шартларының үтәлешен тикшереп тора һәм даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның маршрут карталарын бирә;

4) даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципальара маршруты буенча даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм багаж ташу хокукына ачык конкурсны (алга таба – ачык конкурс) оештыручы функцияләрен башкара, ачык конкурста катнашуга заявкаларның критерийларын бәяләү өчен шкала билгели, йөртүчеләргә даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципальара маршруты буенча пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашыру турында таныклык һәм даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның маршрут карталарын бирә, аларның эшчәнлеген тикшереп тора;

5) Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан, даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның регионара һәм муниципальара маршрутларында башлангыч һәм (яисә) соңгы тукталыш пунктлары буларак файдалану рөхсәт ителә торган тукталыш пунктларының исемлеген төзи;

6) Татарстан Республикасы территориясендә даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм багаж ташу өчен файдаланыла торган транспорт чараларының экологик характеристикаларын билгели һәм раслый;

7) даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципальара маршрутлары реестрларын алып бару тәртибен, даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципальара маршрутларын билгеләү, үзгәртү, туктату тәртибен раслый, даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципальара маршрутлары реестрын алып бара, даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципальара маршрутларын билгели, үзгәртә һәм туктата;

8) Федераль законда каралган очракларда заказ буенча регионара пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашырганда Татарстан Республикасында җирлекләр территориясендә пассажирлар утырту һәм төшерү урыннарын килештерү тәртибен раслый;

9) даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыру һәм аны гамәлгә ашыруны тикшереп тору мәсьәләләре буенча федераль башкарма хакимият органнары, җирле үзидарә органнары белән үзара хезмәттәшлек итә;

10) федераль законнар, әлеге Закон, Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актлары нигезендә аның компетенциясенә кертелгән башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыра.



4 статья. **Даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыру өлкәсендә җирле үзидарә органнарының вәкаләтләре**

Җирле үзидарә органнары даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыру өлкәсендә:

1) үз компетенциясе чикләрендә даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыруны җайга сала торган норматив хокукый актлар кабул итәләр;

2) үз компетенциясе чикләрендә даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны планлаштыру документын әзерләү тәртибен раслыйлар, бу документны кабул итәләр һәм гамәлгә ашыралар;

3) даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципальара маршрутлары буенча даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципаль заказчысы функцияләрен башкаралар, муниципаль контракт төзиләр, муниципаль контракт шартларының үтәлешен тикшереп торалар һәм даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның маршрут карталарын бирәләр;

4) ачык конкурсны оештыручы функцияләрен башкаралар, ачык конкурста катнашуга заявкаларның критерийларын бәяләү өчен шкала билгелиләр, йөртүчеләргә даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм багаж ташу маршруты буенча пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашыру турында таныклык һәм даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның маршрут карталарын бирәләр, аларның эшчәнлеген тикшереп торалар;

5) даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципаль маршрутлары реестрларын алып бару тәртибен, даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципаль маршрутларын билгеләү, үзгәртү, туктату тәртибен раслыйлар, даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципаль маршрутлары реестрын алып баралар, даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципаль маршрутларын билгелиләр, үзгәртәләр һәм туктаталар;

6) муниципаль берәмлекләр территорияләрендә урнашкан, даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципаль маршрутларында башлангыч һәм (яисә) соңгы тукталыш пунктлары буларак файдалану рөхсәт ителә торган тукталыш пунктларының исемлеген төзиләр;

7) вәкаләтле Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органына даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципальара маршрутларында муниципаль берәмлекләр территорияләрендә урнашкан тукталыш пунктларын билгеләү буенча тәкъдимнәр җибәрәләр;

8) даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыру һәм аны гамәлгә ашыруны тикшереп тору мәсьәләләре буенча федераль башкарма хакимият органнары, Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнары белән үзара хезмәттәшлек итәләр;



9) федераль законнар, әлеге Закон, Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актлары нигезендә үз компетенцияләренә кертелгән башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыралар.

5 статья. **Даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципаль маршрутларын, даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципальара маршрутларын билгеләү, үзгәртү, туктату тәртибе**

1. Татарстан Республикасы чикләрендә даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципальара маршрутлары вәкаләтле Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органы тарафыннан билгеләнә, үзгәртелә, туктатыла.

2. Бер шәһәр җирлеге чикләрендә даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципаль маршрутлары тиешле җирлекнең вәкаләтле җирле үзидарә органы тарафыннан билгеләнә, үзгәртелә, туктатыла.

3. Бер муниципаль район составына керә торган ике һәм аннан күбрәк җирлекләр чикләрендә даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципаль маршрутлары тиешле муниципаль районның вәкаләтле җирле үзидарә органы тарафыннан билгеләнә, үзгәртелә, туктатыла.

4. Даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципальара маршрутларын, даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципаль маршрутларын билгеләү, үзгәртү, туктату тәртибе (шул исәптән әлеге маршрутларны билгеләүдән йә үзгәртүдән баш тарту өчен нигезләр, әлеге маршрутларны туктату өчен нигезләр) тиешенчә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты, җирле үзидарә органнары тарафыннан билгеләнә.

5. Даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм багаж ташу маршрутларын билгеләү, үзгәртү, туктату турында карарлар күрсәтелгән карарларны кабул иткән вәкаләтле Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органының яисә вәкаләтле җирле үзидарә органының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтларына урнаштырыла.

6. Даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципаль маршрутын, даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципальара маршрутын туктату турында карар кабул иткән вәкаләтле Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органы яисә вәкаләтле җирле үзидарә органы тиешле маршрут буенча даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашыручы йөртүчеләргә күрсәтелгән

карар үз көченә керергә кимендә 180 көн кала язма рәвештә яисә адресатның хәбәр алуын расларга мөмкинлек бирә торган башка рәвештә әлеге карар турында хәбәр итәргә тиеш.

7. Даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципальара маршрутларын билгеләгән вәкаләтле Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органы даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципальара маршрутлары реестрын алып бара.

8. Үз компетенциясе чикләрендә даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципаль маршрутларын билгеләгән вәкаләтле җирле үзидарә органы тиешле муниципаль берәмлектә даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципаль маршрутлары реестрын алып бара.

9. Даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм багаж ташу маршрутлары реестрларына Федераль законның 26 статьясында билгеләнгән белешмәләр кертелгән булырга тиеш.

10. Даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм багаж ташу маршрутлары реестрларына кертелгән белешмәләр әлеге реестрларны алып бару вәкаләтләре бирелгән вәкаләтле Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органының яисә вәкаләтле җирле үзидарә органының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтларына урнаштырыла.

6 статья. **Даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыру**

1. Халыкның транспорт хезмәте күрсәтүләрдән файдалана алуын тәэмин итү максатларында Федераль закон нигезендә вәкаләтле Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органы, вәкаләтле җирле үзидарә органнары җайга салына торган тарифлар буенча һәм җайга салынмый торган тарифлар буенча даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм багаж ташу өчен даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципаль маршрутларын, даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципальара маршрутларын билгелиләр.

2. Җайга салына торган тарифлар буенча даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм багаж ташу вәкаләтле Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органы яисә вәкаләтле җирле үзидарә органы, Федераль закон нигезләмәләрен исәпкә алып, дәүләт ихтыяҗларын һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә дәүләт контрактлары яисә муниципаль контрактлар төзү юлы белән гамәлгә ашырыла.



3. Даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципальара, муниципаль маршрутлары буенча даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның җайга салына торган тарифлары Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең тарифларны җайга салу өлкәсендә вәкаләтле органы тарафыннан билгеләнә.

4. Даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципаль маршрутлары, даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципальара маршрутлары буенча җайга салынмый торган тарифлар белән даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм багаж ташу хокукы Федераль законда билгеләнгән тәртиптә үткәрелә торган ачык конкурс нәтиҗәләре буенча бирелгән даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның тиешле маршруты буенча пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашыру турында таныклык һәм даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның тиешле маршрут карталары белән раслана.

7 статья. **Даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм багаж ташу маршруты буенча пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашыру турында таныклык бирү һәм аның гамәлдә булуын туктату, тиешле маршрут карталарын бирү**

1. Даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципаль маршруты, даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципальара маршруты буенча пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашыру турында таныклык һәм тиешле маршрут карталары әлеге маршрутларны билгеләгән вәкаләтле Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органы яисә вәкаләтле җирле үзидарә органнары тарафыннан бирелә.

2. Даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципаль маршруты, даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципальара маршруты буенча пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашыру турында таныклык һәм тиешле маршрут карталары ачык конкурс нәтиҗәләре буенча Федераль законда билгеләнгән тәртиптә бирелә.

3. Даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципаль маршруты, даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципальара маршруты буенча пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашыру турында таныклык һәм тиешле маршрут карталары, әгәр алар даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашыру

өчен билгеләнгән булса, ачык конкурс үткәрмичә генә түбәндәге очракларда бирелә:

1) Федераль законның 29 статьясындагы 1 өлешенең 1 һәм 2 пунктларында каралган шартлар барлыкка килгәннән алып даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны ачык конкурс үткәрү нәтиҗәләре буенча бирелгән даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм багаж ташу маршруты буенча пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашыру турында яңа таныклык нигезендә гамәлгә ашыра башлаганчы;

2) гадәттән тыш хәл шартларында халыкка транспорт хезмәте күрсәтүне тәэмин итү өчен билгеләнгән даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм багаж ташу маршруты буенча.

4. Даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм багаж ташу маршруты буенча пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашыру турында таныклык һәм даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның маршрут карталары ачык конкурс үткәрмичә генә бер тапкыр 180 көннән артыграк булмаган срокка, аларны бирү өчен нигез булган шартлар барлыкка килгән көндә бирелә.

5. Федераль законның 29 статьясындагы 1 өлешендә каралган шартларның берсе генә барлыкка килгән очракта да даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм багаж ташу маршруты буенча пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашыру турында таныклыкның гамәлдә булуы Федераль законның 29 статьясындагы 2 – 4 өлешләрендә билгеләнгән тәртиптә туктатыла.

6. Даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм багаж ташу маршруты буенча пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашыру турында таныклыкны биргән вәкаләтле Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органы яисә вәкаләтле җирле үзидарә органы түбәндәге шартларның кимендә берсе барлыкка килгән очракта әлеге таныклыкның гамәлдә булуын туктату турында гариза белән судка мөрәҗәгать итә:

1) даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм багаж ташу маршруты буенча әлеге таныклыкта каралган даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм багаж ташу гадәттән тыш хәлләр булмаган вакытта рәттән өч көннән артыграк вакыт дәвамында үтәлмәсә, ә пассажирлар йөртү һәм багаж ташу вәкаләтле федераль башкарма хакимият органы билгеләгән даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның регионара маршрутлары буенча гамәлгә ашырылган очракта, рәттән кимендә биш рейс үтәлмәсә;

2) әлеге таныклык бирелгән юридик зат, индивидуаль эшкуар яисә гади ширкәт шартнамәсенең кимендә бер катнашучысы әлеге таныклыкта каралган пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашырганда Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 11.33 статьясындагы 3 – 5 өлешләрендә каралган административ хокук бозуларны кылган өчен бер ел дәвамында берничә тапкыр административ җаваплылыкка тартылса;

3) гади ширкәт шартнамәсе өзелсә (әлеге таныклык гади ширкәт шартнамәсе катнашучыларына бирелгән очракта);

4) машина йөртүче гаебе белән кеше сәламәтлегенә авыр зыян салган яисә кеше үлеменә китергән юл-транспорт һәлакәте булса;

5) йөртүче Федераль законның 37 статьясында билгеләнгән тәртиптә даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм багаж ташу турында квартал саен бирелергә тиешле хисапны рәттән ике тапкыр тапшырмаса.

8 статья. **Даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм багаж ташу өчен файдаланыла торган транспорт чарасын төнгә кую урыны**

1. Татарстан Республикасы чикләрендә төнге парковкаларның урыннары җирле үзидарә органнары тәкъдимнәре буенча вәкаләтле Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органы тарафыннан билгеләнә.

2. Төнге парковкаларның урыннары турында белешмәләр вәкаләтле Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтына урнаштырыла.

9 статья. **Әлеге Закон нигезләмәләрен гамәлгә ашыруны тәэмин итү**

1. Даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм багаж ташу хокукы әлеге Закон үз көченә кергән көнгә кадәр гамәлдә булган тәртип нигезендә барлыкка килгән йөртүчеләр белән дәвамлы хокук мөнәсәбәтләре кысаларында даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыру Федераль законның 39 статьясында билгеләнгән срокларны исәпкә алып башкарыла.

2. Федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә инвалидларга (кресло-коляскаларда йөрүче һәм сукырларны йөртә торган этләрдән файдаланучы инвалидларны да кертеп) автомобиль транспортыннан һәм шәһәр җир өсте электр транспортыннан тоткарлыксыз файдалана алу, транспорт инфраструктурасы объектларына керә алу өчен шартлар тәэмин ителә.

10 статья. **Татарстан Республикасы аерым закон актларының (закон актлары нигезләмәләренең) үз көчләрен югалтуын тану**

Түбәндәгеләрне үз көчләрен югалткан дип танырга:

1) «Татарстан Республикасы территориясендә гомуми файдаланудагы автомобиль һәм шәһәр җир өсте электр транспортында пассажирлар йөртүне оештыру турында» 2006 елның 13 ноябрендәге 70-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2006, № 11 (I өлеш); 2007, № 11; 2009, № 6; 2012, № 1, № 11 (I өлеш); 2014, № 12 (II өлеш);

2) «Татарстан Республикасы территориясендә гомуми файдаланудагы автомобиль һәм шәһәр җир өсте электр транспортында пассажирлар йөртүне оештыру турында» Татарстан Республикасы Законының 10 статьясына үзгәреш кертү хакында» 2007 елның 7 ноябрендәге 47-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2007, № 11);

3) «Тарифлар буенча Татарстан Республикасы комитеты төзелүгә бәйле рәвештә Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2009 елның 29 июнендәге 24-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 2 статьясын (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2009, № 6);

4) «Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексының 5.6 статьясына үзгәреш кертү һәм «Татарстан Республикасы территориясендә гомуми файдаланудагы автомобиль һәм шәһәр җир өсте электр транспортында пассажирлар йөртүне оештыру турында» Татарстан Республикасы Законының 11 статьясындагы 6 өлешенең үз көчен югалтуын тану хакында» 2012 елның 13 гыйнварындагы 7-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 2 статьясын (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2012, № 1);

5) «Татарстан Республикасы территориясендә гомуми файдаланудагы автомобиль һәм шәһәр җир өсте электр транспортында пассажирлар йөртүне оештыру турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 2012 елның 2 ноябрендәге 75-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2012, № 11 (I өлеш);

6) «Татарстан Республикасы территориясендә гомуми файдаланудагы автомобиль һәм шәһәр җир өсте электр транспортында пассажирлар йөртүне оештыру турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 2014 елның 15 декабрендәге 116-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2014, № 12 (II өлеш).

11 статья. **Әлеге Законның үз көченә керү тәртибе**

1. Әлеге Закон, шушы статья белән үз көчләренә керүнең бүтән сроклары билгеләнгән нигезләмәләреннән тыш, рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.
2. Әлеге Законның 5 – 7 статьялары 2016 елның 11 гыйнварыннан үз көченә керә.
3. Әлеге Законның 8 статьясы 2016 елның 15 июленнән үз көченә керә.
4. Әлеге Законның 9 статьясындагы 2 өлеше нигезләмәләре 2016 елның 1 июленнән яңа гына кулланылышка тапшырылган яисә реконструкция, модернизация узган объектларга карата гына кулланыла.
5. Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары 2016 елның 11 гыйнварына кадәр Татарстан Республикасы норматив хокукый актларын Федераль закон һәм әлеге Закон нигезләмәләренә туры китерергә тиеш.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2015 елның 26 декабре
№ 107-ТРЗ

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

### 1256. Татарстан Республикасында шәһәр, авыл җирлекләренең җирле үзидарә органнары һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары арасында дәүләт милке чикләнмәгән җир кишәрлекләре белән эш итү вәкаләтләрен яңадан бүлү турында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2015 елның 23 декабрендә
кабул ителде

**1 статья**

Әлеге Закон, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6

октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 17 статьясындагы 1[2] өлешенә, Россия Федерациясе Җир кодексының 10[1] статьясына һәм «Россия Федерациясе Җир кодексын гамәлгә кертү турында» 2001 елның 25 октябрендәге 137-ФЗ номерлы Федераль законның 2 статьясындагы 4 пунктына, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына нигезләнеп, җирдән файдалану һәм җирлектә төзелеш алып бару кагыйдәләре расланган Татарстан Республикасында шәһәр, авыл җирлекләре (алга таба — шәһәр, авыл җирлекләре) җирле үзидарә органнарының дәүләт милке чикләнмәгән, шәһәр, авыл җирлекләре территориясендә урнашкан җир кишәрлекләре белән эш итү вәкаләтләрен шәһәр, авыл җирлекләре җирле үзидарә органнары белән Татарстан Республикасы дәүләт органнары арасында биш елга яңадан бүлә.

**2 статья**

Әлеге Законның 1 статьясында күрсәтелгән вәкаләтләр Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты яисә ул вәкаләтләр биргән Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органы тарафыннан гамәлгә ашырыла.

**3 статья**

Әлеге Закон 2016 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2015 елның 26 декабре
№ 108-ТРЗ



## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

### 1257. Татарстан Республикасы муниципаль районнарының җирле үзидарә органнарына дәүләт милке чикләнмәгән җир кишәрлекләре белән эш итү буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен бирү турында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2015 елның 23 декабрендә
кабул ителде

Әлеге Закон «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актлары нигезендә Татарстан Республикасы муниципаль районнарының җирле үзидарә органнарына (алга таба — җирле үзидарә органнары) дәүләт милке чикләнмәгән җир кишәрлекләре белән эш итү буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен бирә.

1 статья. Җирле үзидарә органнарына бирелә торган Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләре

Җирле үзидарә органнарына муниципаль район составына керә торган, җирдән файдалану һәм җирлек төзү кагыйдәләре расланган шәһәр, авыл җирлекләре территорияләрендә урнашкан, дәүләт милке чикләнмәгән җир кишәрлекләре белән эш итү буенча, җир кишәрлекләрен региональ яисә муниципальара әһәмияттәге автомобиль юллары урнаштыру өчен бирү вәкаләтләреннән тыш, Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләре (алга таба — дәүләт вәкаләтләре) бирелә.

2 статья. **Җирле үзидарә органнарына дәүләт вәкаләтләре бирелә торган Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре исемнәре**

Дәүләт вәкаләтләре Татарстан Республикасының түбәндәге муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнарына бирелә:

Әгерҗе муниципаль районы, Азнакай муниципаль районы, Аксубай муниципаль районы, Актаныш муниципаль районы, Алексеевск муниципаль районы, Әлки муниципаль районы, Әлмәт муниципаль районы, Апас муниципаль районы, Арча муниципаль районы, Әтнә муниципаль районы, Баулы муниципаль районы, Балтач муниципаль районы, Бөгелмә муниципаль районы, Буа муниципаль районы, Югары Ослан муниципаль районы, Биектау муниципаль районы, Чүпрәле муниципаль районы, Алабуга муниципаль районы, Зәй муниципаль районы, Зеленодольск муниципаль районы, Кайбыч муниципаль районы, Кама Тамагы муниципаль районы, Кукмара муниципаль районы, Лаеш муниципаль районы, Лениногорск муниципаль районы, Мамадыш муниципаль районы, Менделеевск муниципаль районы, Минзәлә муниципаль районы, Мөслим муниципаль районы, Түбән Кама муниципаль районы, Яңа Чишмә муниципаль районы, Нурлат муниципаль районы, Питрәч муниципаль районы, Балык Бистәсе муниципаль районы, Саба муниципаль районы, Сарман муниципаль районы, Спас муниципаль районы, Тәтеш муниципаль районы, Тукай муниципаль районы, Теләче муниципаль районы, Чирмешән муниципаль районы, Чистай муниципаль районы, Ютазы муниципаль районы.

3 статья. **Җирле үзидарә органнарына дәүләт вәкаләтләре бирелә торган чор**

Җирле үзидарә органнарына дәүләт вәкаләтләре биш елга бирелә.

4 статья. **Җирле үзидарә органнарына тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен финанс ягыннан тәэмин итү**

1. Җирле үзидарә органнарына тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен финанс белән тәэмин итү Татарстан Республикасы бюджетыннан муниципаль районнар бюджетларына бирелә торган субвенцияләр исәбеннән гамәлгә ашырыла.

2. Җирле үзидарә органнары тарафыннан дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан муниципаль районнар бюджетларына бирелә торган субвенцияләр күләмен исәпләп чыгару Җирле үзидарә органнары тарафыннан дәүләт милке чикләнмәгән җир кишәрлекләре белән эш итү буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан муниципаль районнар бюджетларына бирелә торган субвенцияләрнең



күләмен исәпләп чыгару методикасы нигезендә әлеге Законга кушымта буенча башкарыла.

3. Җирле үзидарә органнары тарафыннан дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан муниципаль районнар бюджетларына бирелә торган субвенцияләр күләме чираттагы финанс елына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законы белән билгеләнә.

5 статья. **Дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен җирле үзидарә органнарына түләүсез файдалануга тапшырыла торган матди чаралар**

1. Татарстан Республикасы милкендәге матди чаралар җирле үзидарә органнары тарафыннан дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруны тәэмин итү кирәк булганда, Тапшырыла торган матди чаралар исемлеге нигезендә җирле үзидарә органнарына түләүсез файдалануга тапшырыла.

2. Тапшырыла торган матди чаралар исемлеген әзерләү, раслау һәм матди чараларны тапшыру турында карар кабул итү Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең җир мөнәсәбәтләре өлкәсендәге вәкаләтле органы тарафыннан җирле үзидарә органнары тәкъдимнәрен исәпкә алып башкарыла.

6 статья. **Дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашырганда җирле үзидарә органнарының хокуклары һәм бурычлары**

1. Җирле үзидарә органнары дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашырганда түбәндәгеләргә хокуклы:

1) муниципаль берәмлекнең уставында каралган очракларда һәм тәртиптә дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен өстәмә рәвештә үз матди һәм финанс чараларыннан файдаланырга;

2) дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга бәйле эшчәнлекне камилләштерү буенча тәкъдимнәр кертергә;

3) Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарында дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча мәгълүмати, консультатив, оештыру һәм методик ярдәм алырга.

2. Җирле үзидарә органнары дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашырганда түбәндәгеләрне үтәргә тиеш:

1) Россия Федерациясе законнары һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашырырга;

2) Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең вәкаләтле органнарына дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга бәйле документлар һәм кирәкле мәгълүмат бирергә;

3) Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең җир мөнәсәбәтләре өлкәсендәге вәкаләтле органына квартал саен дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру турында хисаплар тапшырырга;

4) җирле үзидарә органнарының дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруларын тикшереп торуны башкаруда Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең вәкаләтле органнарына кирәкле ярдәм күрсәтергә.

7 статья. **Җирле үзидарә органнары дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашырганда Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының хокуклары һәм бурычлары**

1. Җирле үзидарә органнары дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашырганда Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары түбәндәгеләргә хокуклы:

1) җирле үзидарә органнарыннан һәм (яисә) җирле үзидарә органнарының вазыйфаи затларыннан дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга бәйле мәсьәләләр буенча документлар һәм мәгълүмат соратып алырга;

2) җирле үзидарә органнарының дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру буенча эшчәнлеген тикшерергә;

3) җирле үзидарә органнары һәм (яисә) җирле үзидарә органнарының вазыйфаи затлары тарафыннан дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча ачыкланган закон бозуларны бетерү буенча язма күрсәтмәләр бирергә.

2. Җирле үзидарә органнары дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашырганда Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары түбәндәгеләрне үтәргә тиеш:

1) җирле үзидарә органнарына дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен кирәкле матди һәм финанс чараларын тапшырырга;

2) җирле үзидарә органнарының дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруларын, шулай ук шушы максатларга бирелгән матди һәм финанс чараларыннан файдалануны тикшереп торуны башкарырга;

3) җирле үзидарә органнары тарафыннан дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча мәгълүмати, консультатив, оештыру һәм методик ярдәм күрсәтергә.



8 статья. **Дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру турында җирле үзидарә органнарының хисап бирү тәртибе**

Дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру турында хисаплар җирле үзидарә органнары тарафыннан Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең җир мөнәсәбәтләре өлкәсендәге вәкаләтле органына Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты билгеләгән рәвештә хисап кварталыннан соң килә торган айның 10 числосына кадәр тапшырыла.

9 статья. **Җирле үзидарә органнары тарафыннан дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруны тикшереп тору**

Җирле үзидарә органнары тарафыннан дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруны тикшереп тору түбәндәгечә башкарыла:

1) Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең җир мөнәсәбәтләре өлкәсендәге вәкаләтле органы тарафыннан — дәүләт вәкаләтләрен тиешенчә гамәлгә ашыру өлешендә, түбәндәге юллар белән:

а) дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру турында кирәкле документлар, хисаплар һәм мәгълүмат соратып алу;

б) дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру буенча җирле үзидарә органнары эшчәнлегенә шушы орган тарафыннан ел саен раслана торган план нигезендә күчмә тикшерүләр, шулай ук, кирәк булганда, планнан тыш күчмә тикшерүләр үткәрү;

2) Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең финанс сәясәте өлкәсендә вәкаләтле органы тарафыннан — дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен тапшырылган финанс чараларыннан максатчан файдалану өлешендә, түбәндәге юллар белән:

а) дәүләт вәкаләтләрен башкару турында кирәкле документларны, хисапларны һәм мәгълүматны соратып алу;

б) дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру буенча җирле үзидарә органнары эшчәнлегенә, кирәк булганда, күчмә тикшерүләр үткәрү, шул исәптән элек соратып алынган документларны, хисапларны, мәгълүматны карау нәтиҗәләре буенча, шулай ук закон бозуның ачыкланган фактларына бәйле рәвештә дә;

в) законнар бозуларны бетерү һәм аларны кисәтү буенча тиешле чаралар күрү;

3) җирле үзидарә органнарына дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен Татарстан Республикасы милкендәге матди чараларны түләүсез файдалануга тапшырган очракта, Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең җир мөнәсәбәтләре өлкәсендә вәкаләтле органы тарафыннан — җирле үзидарә органнарына

дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен тапшырылган дәүләт мөлкәтен саклау һәм аннан тиешенчә файдалану өлешендә, түбәндәге юллар белән:

а) дәүләт вәкаләтләрен башкару турында кирәкле документларны, хисапларны һәм мәгълүматны соратып алу;

б) дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру буенча җирле үзидарә органнары эшчәнлегенә, кирәк булганда, тикшерүләр үткәрү, шул исәптән элек соратып алынган документларны, хисапларны һәм мәгълүматны карау нәтиҗәләре буенча, шулай ук закон бозуның ачыкланган фактларына бәйле рәвештә дә;

в) законнар бозуларны бетерү һәм аларны кисәтү буенча тиешле чаралар күрү.

10 статья. **Җирле үзидарә органнары тарафыннан дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруны туктату шартлары һәм тәртибе**

1. Җирле үзидарә органнары тарафыннан дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруны туктату түбәндәге очракларда Татарстан Республикасы законы белән башкарыла:

1) җирле үзидарә органнары дәүләт вәкаләтләрен җайга салу өлкәсендәге законнар таләпләрен үтәмәгәндә яисә тиешенчә үтәмәгәндә;

2) җирле үзидарә органнары һәм (яисә) җирле үзидарә органнарының вазыйфаи затлары әлеге Закон таләпләрен бозуларны бетерү турындагы күрсәтмәләрне үтәмәгәндә;

3) Россия Федерациясе законнары яисә Татарстан Республикасы законнары җирле үзидарә органнары тарафыннан дәүләт вәкаләтләрен үтәү мөмкинлеген юкка чыгарырлык итеп үзгәртелгәндә.

2. Җирле үзидарә органнары тарафыннан дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруны туктату дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен тапшырылган Татарстан Республикасы милкендәге файдаланылмаган финанс чараларын һәм матди чараларны кире кайтаруны таләп итә.

3. Җирле үзидарә органнары дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру буенча законнар таләпләрен үтәмәгән яисә тиешенчә үтәмәгән очракта, Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең җир мөнәсәбәтләре өлкәсендәге вәкаләтле органы, күрсәтелгән хокук бозулар ачыкланган көннән алып 10 көн эчендә җирле үзидарә органнарына аларны бетерү турында күрсәтмә җибәрә.

4. Ачыкланган хокук бозуларны бетерү турындагы күрсәтмә җирле үзидарә органнарына кергән көннән алып ун көннән дә



соңга калмыйча мәҗбүри рәвештә каралырга тиеш. Күрсәтмәне карау нәтиҗәләре хакында Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең җир мөнәсәбәтләре өлкәсендәге вәкаләтле органына кичекмәстән язма рәвештә хәбәр ителә.

5. Әлеге статьяның 1 өлешендә каралган очракларда, Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең җир мөнәсәбәтләре өлкәсендәге вәкаләтле органы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каравына җирле үзидарә органнары тарафыннан дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруны туктату турында тәкъдим һәм тиешле Татарстан Республикасы законы проектын кертә.

11 статья. **Йомгаклау нигезләмәләре**

1. Әлеге Закон 2016 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

2. Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының һәм җирле үзидара органнарының норматив хокукый актлары әлеге Закон үз көченә кергән көненнән алып өч ай эчендә аңа туры китерелергә тиеш.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2015 елның 26 декабре
№ 109-ТРЗ

«Татарстан Республикасы
муниципаль районнарының
җирле үзидарә органнарына
дәүләт милке чикләнмәгән
җир кишәрлекләре белән эш итү буенча
Татарстан Республикасы дәүләт
вәкаләтләрен бирү турында»
Татарстан Республикасы Законына
кушымта

Җирле үзидарә органнары тарафыннан дәүләт милке чикләнмәгән җир кишәрлекләре белән эш итү буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан муниципаль районнар бюджетларына бирелә торган субвенцияләрнең күләмен исәпләп чыгару
МЕТОДИКАСЫ

1. Әлеге Методика җирле үзидарә тарафыннан дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен Татарстан Республикасы бюд-

жетыннан муниципаль районнарның бюджетларына бирелә торган субвенцияләрне исәпләп чыгару өчен билгеләнә.

2. Җирле үзидарә органнары тарафыннан дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан j муниципаль районына бирелә торган субвенцияләр күләме түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$C_j^z = N^z \times H_j,$$

монда:

$C_j^z$ — Татарстан Республикасы бюджетыннан j муниципаль районына җирле үзидарә органнары тарафыннан дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен бирелә торган субвенцияләр күләме.

$N^z$ — җирле үзидарә органнары тарафыннан дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен j муниципаль районына дәүләт милке чикләнмәгән бер гектар җир кишәрлегенә субвенция күләмен билгеләү өчен норматив (бер гектарга сум);

$H_j$ — j муниципаль районында дәүләт милке чикләнмәгән җир кишәрлекләре мәйданы (гектар).

3. җирле үзидарә органнары тарафыннан дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен j муниципаль районына бирелә торган субвенцияләр күләмен билгеләү өчен норматив түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$N^z = \frac{R}{\sum_{j=1}^{n} H_j},$$

монда:

R — җирле үзидарә органнары тарафыннан дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга фаразланган чыгымнар.

n — муниципаль районнар саны.

4. Җирле үзидарә органнары тарафыннан дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга фаразланган чыгымнар түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$R = \left(\sum_{j=1}^{n} S_j \times t_{усл.}\right) \times Z_1,$$



монда:

$S_j$ — j муниципаль районында дәүләт милке чикләнмәгән җир кишәрлеген бирү буенча бер елда күрсәтелгән хезмәтләр саны;

$t_{усл.}$ — j муниципаль районы башкарма комитетының баш белгече тарафыннан хезмәт күрсәтү өчен кирәкле вакыт (ике эш көне күләмендә билгеләнә);

$Z_1$ — j муниципаль районы башкарма комитеты баш белгеченә, хезмәт өчен түләү фондына кучерелгән акчаны да кертеп, бер эш көне өчен түләнгән эш хакы.

5. j муниципаль районында бер елда күрсәтелә торган хезмәтләр саны түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$S_j = K_{ср} \times H_j,$$

монда:

$K_{ср}$ — дәүләт милке чикләнмәгән җир кишәрлеген бирү буенча хезмәт күрсәтүгә бер гектарга туры килә торган мөрәҗәгатьләрнең уртача санын билгели торган коэффициент, ул 0,005 кә тигез.

# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

## 1258. Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексының 8.2 статьясына үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2015 елның 23 декабрендә
кабул ителде

**1 статья**

Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексының 8.2 статьясына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2006, № 12 (I өлеш); 2007, № 11; 2009, № 2, № 7 – 8 (I өлеш), № 9 – 10, № 12 (I өлеш); 2010, № 1 – 2, № 3, № 6 (I өлеш), № 7 (I өлеш), № 7 (II өлеш), № 10 (II өлеш); 2011, № 6 (I өлеш), № 8 (I өлеш), № 10 (I өлеш), № 11 (I өлеш); 2012, № 1, № 6 (I өлеш), № 7 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2013, № 1, № 2 (I өлеш), № 6 (II өлеш), № 7,

№ 10; 2014, № 1 – 2, № 5, № 6 (I өлеш), № 7, № 12 (III өлеш); 2015, № 3, № 4) үзгәреш кертеп, аны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«8.2 статья. **Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексында каралган административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә вәкаләтле вазыйфаи затлар**

1. Региональ дәүләт контролен (күзәтчелеген), дәүләт финанс контролен, шулай ук федераль дәүләт күзәтчелеге өлкәсендә тапшырылган вәкаләтләрне гамәлгә ашырганда Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 19.4 статьясындагы 1 өлешендә, 19.4[1] статьясындагы 1 өлешендә, 19.5 статьясындагы 1 өлешендә, 19.7 статьясында каралган административ хокук бозулар турында беркетмәләрне Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары җитәкчеләре һәм аларның урынбасарлары, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарының структур бүлекчәләре җитәкчеләре һәм белгечләре, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарының территориаль органнары җитәкчеләре һәм белгечләре, шулай ук вазыйфаи бурычларына эшчәнлекнең тиешле өлкәсендә дәүләт контролен (күзәтчелеген), дәүләт финанс контролен гамәлгә ашыру керә торган башка вазыйфаи затлар төзи.

2. Муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 19.4 статьясындагы 1 өлешендә, 19.4[1] статьясында, 19.5 статьясының 1 өлешендә, 19.7 статьясында каралган хокук бозулар турында беркетмәләрне түбәндәгеләр төзи:

1) муниципаль районнарда, шәһәр округларында – муниципаль районнарның, шәһәр округларының башкарма комитетлары җитәкчеләре, аларның беренче урынбасарлары, урынбасарлары, муниципаль районнарның, шәһәр округларының башкарма комитетларындагы структур бүлекчәләр җитәкчеләре, аларның урынбасарлары, шулай ук муниципаль районнардагы, шәһәр округларындагы башкарма комитетларның үз вазыйфаларына муниципаль контрольне гамәлгә ашыру керә торган башка вазыйфаи затлары;

2) җирлекләрдә – җирлекләр башлыклары, җирлекләрнең башкарма комитетлары җитәкчеләре, җирлекләрдәге башкарма комитетлар җитәкчеләренең урынбасарлары (секретарьлар), шулай ук җирлекләрдәге башкарма комитетларның үз вазыйфаларына муниципаль контрольне гамәлгә ашыру керә торган башка вазыйфаи затлары.



3. Муниципаль берәмлекләрдә муниципаль финанс контролен гамәлгә ашырганда Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 5.21, 15.1, 15.11, 15.14 – 15.15[16] статьяларында, 19.4 статьясындагы 1 өлешендә, 19.4[1] статьясында, 19.5 статьясындагы 20 өлешендә, 19.6 һәм 19.7 статьяларында каралган административ хокук бозулар турында беркетмәләрне муниципаль берәмлекләрдәге контроль-хисап органнарының, башкарма комитетларның, финанс органнарының үз вазыйфаи бурычларына муниципаль финанс контролен гамәлгә ашыру керә торган вазыйфаи затлары төзи.».

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2015 елның 29 декабре
№ 110-ТРЗ